**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлегенең Саклаубаш торак пунктында
2026 елда үзара салым кертү турында

**14.11.2025** **№ 2**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Саклаубаш авылында 2026 нче елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында" Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге башлыгының 2025 елның 31 октябрендәге 3 номерлы карары нигезендә 2025 елның 14 ноябрендә 10.00 сәгатьтә узган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең Саклаубаш авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Саклаубаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданга, I төркем инвалидларыннан тыш, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш 2026 елда үзара салым акчаларын кертергә, һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрергә:

1) Халыкның массакүләм ял итү урыннарын төзекләү (төзелеш материаллары сатып алу һәм ял паркы салу, триммер сатып алу, тримерга ягулык материаллары сатып алу)

2) Торак пункт территориясен төзекләндерү (территорядәге үләннәрне чабу, килешү буенча эш һәм күрсәтелгән хезмәтләрне түләү)

3) Саклаубаш торак пунктына урам яктырту челтәрләрен ясау (лампалар сатып алу һәм алыштыру)

4) Автомобиль юлларын карап тору өчен МТЗ-82.1 махсус техникасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт хакы түләү, юлларны кардан чистарту, үлән чабу)

2. Әлеге карарны Саклаубаш авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Л.М.Габидуллина